# Татарстан Республикасы
# Дәүләт Советы Президиумы

# КАРАРЫ

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык бишенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык бишенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. “Җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында” 527-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

2. “Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 532-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

3. “2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында” 530-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

4. “2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында” 531-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

5. “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 494-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (III укылыш).

6. “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлеге турында” 497-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

7. “Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 534-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 535-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. “Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәреш кертү турында” 529-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. “Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында” 523-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. “Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 123 статьясына үзгәреш кертү турында” 313495-6 номерлы федераль закон проекты хакында (18 яшькә кадәрге инвалид баласы булган ата-аналарга (опекуннарга, попечительләргә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга) үзләренә уңайлы вакытта еллык түләүле отпуск бирү турында).

12. “Сәяси репрессия корбаннарын реабилитацияләү турында” Россия Федерациясе Законының 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 316538-6 номерлы федераль закон проекты турында (реабилитацияләнгән затларны һәм аларның гаилә әгъзаларын торак урыннар белән тәэмин итү хакындагы норманы төгәлләштерү).

13. “Бөек Ватан сугышы балалары статусы турында” федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча халык депутатларының Орел өлкә Советы закон чыгару инициативасы хакында.

14. “Күңел ачу хезмәтләре күрсәтелгәндә музыкаль әсәрләр башкаручыларның фонограмма куллануы турында кулланучыларга хәбәр итүне тәэмин итү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 299577-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

15. Хөкүмәт сәгате: “2014 елда коммуналь һәм торак хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә тариф җайга салуы турында”.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2013 елның 16 октябре
№ 3122-IV ДС